СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**23 сентябрь 2020 ел** **№ 3**

## "Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында" Арча район Советының 2005 елның 31 октябрендәге 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2014 елның 19 сентябрендәге 286 номерлы үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексы» Федераль закон нигезендә Арча район Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Арча район Советының 2005 елның 31 октябрендәге 1 номерлы «Арча муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында" карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә (19.09.2014 ел, № 286 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «8. Конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүче, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 13 статьясында билгеләнгән муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр сыйфатындагы шартлар булмаганда, 18 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданнары ия.»;

2) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «12. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы конкурс комиссиясенә түбәндәге документларны тапшыра:

1) конкурс комиссиясе рәисе исеменә язылган шәхси гариза;

2) әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы итеп бирелгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;

3) паспорт яисә аны алмаштыручы документ күчермәсе;

4) тиешле һөнәри белем, эш стажы һәм квалификацияне раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат

нотариаль яки кадрлар хезмәтләре тарафыннан расланган һөнәри белем турында документлар күчермәләре, шулай ук граждан теләге буенча өстәмә һөнәри белем бирү турында, гыйльми дәрәҗә бирү турында, хезмәт итү урыны буенча гыйльми исем бирү турында документлар күчермәләре;

5) граждан җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кергән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгәндә, муниципаль хезмәткәрләр әлеге белешмәләрне тапшырырга тиешле җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларында билгеләнгән форма буенча муниципаль хезмәткә керү елына кадәрге ел өчен керемнәре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының муниципаль хезмәткә керү елына кадәрге ел өчен керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

6) гражданның муниципаль хезмәткә керүгә яисә аны узуга комачаулаучы авыруларның булмавы турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен билгеләнгән форма буенча медицина оешмасы бәяләмәсе;

7) Физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык;

8) хәрби исәпкә алу документлары - запаста торучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

9) шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

10) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_1 статьясында каралган белешмәләр;

11) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

3) 27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә "27. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр конкурс тәмамланганнан соң 7 көн эчендә кандидатларга язма рәвештә җибәрелә".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы — И.Г. Нуриев

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә 1 нче кушымта

# АНКЕТА

| | |
|---|---|
| 1. Фамилиясе ______<br>Исем ______<br>Атасының исеме ______ | Фото өчен урын |

| | |
|---|---|
| 2. Фамилия, исем яки ата исемен үзгәрткән очракта, аларны, шулай ук нинди сәбәп белән үзгәрткәнне күрсәтегез | |
| 3. Туган ел, ай, көн, урын (авыл, шәһәр, район, өлкә, край, республика, ил) | |
| 4. Гражданлык (әгәр үзгәртсәгез, башка дәүләт гражданлыгына ия булсагыз, кайчан һәм нинди сәбәпләр аркасында үзгәрүен күрсәтегез) | |
| 5. Белем (кайчан һәм нинди уку йортлары тәмамладыгыз, диплом номерлары)<br><br>Әзерлек юнәлеше яки диплом буенча һөнәр<br><br>Диплом буенча квалификация | |
| 6. Югары уку йортыннан соң һөнәри белем: аспирантура, адъюнктура, докторантура (белем бирү яки фәнни учреждениенең исеме, тәмамлау елы)<br><br>Гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем (бирелү вакыты, дипломнар, аттестатлар номерлары) | |

| | |
|---|---|
| 7. Нинди чит телләр һәм Россия Федерациясе халыкларының телләре һәм нинди дәрәҗәдә (сүзлек белән укыйсыз һәм тәрҗемә итәсез, укыйсыз һәм иркен аралаша аласыз) беләсез | |
| 8. Федераль граждан хезмәтенең класс чиннары, дипломатик ранглар, хәрби яисә махсус исем, хокук саклау хезмәтенең класс чиннары, Россия Федерациясе субъекты граждан хезмәтенең класс чиннары, дәүләт хезмәтенең квалификация разряды, муниципаль хезмәтнең квалификация разряды һәм класс чиннары (кем һәм кайчан бирелгән һәм кем тарафыннан) | |
| 9. Хөкем ителдегезме, кайчан һәм ни өчен (Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенә кергәндә тутырыла) | |
| 10. Эш, хезмәт, уку дәверендә дәүләт серен белү, аның формасы, номеры һәм датасы (әгәр булса) | |

11. Хезмәт эшчәнлеге башланганнан бирле башкарыла торган эш (югары һәм урта махсус уку йортларында уку, хәрби хезмәт, эшмәкәрлек эшчәнлеге һ.б.).

Әлеге пунктны тутырганда оешманы шул вакытта аталганча, хәрби хезмәт вазыйфасын һәм хәрби частьнең номерын күрсәтеп язарга кирәк.

| Ай һәм ел | | Оешманы күрсәтеп вазыйфа | Оешманың адресы (шул исәптән чит илдәге) |
|---|---|---|---|
| керү | китү | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

12. Дәүләт бүләкләре, башка аерымлык билгеләре

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

13. Туганнарыгыз (ата, ана, кыз һәм ир туганнар, балалар), шулай ук ир (хатын), шул исәптән аерылган, кыз һәм ир туганнарның ире (хатыны), ирнең (хатынның) кыз һәм ир туганнары

Әгәр туганнарыгыз фамилиясен, исемен, этисенең исемен үзгәртсә, шулай ук аларның элекке фамилиясен, исемен, этисенең исемен күрсәтергә кирәк.

| Туганлык дәрәҗәсе | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Елы,ае, көне һәм туган урыны | Эш урыны (оешманың исеме һәм адресы), вазыйфасы | Өй адресы (теркәлү адресы, фактта яшәү адресы) |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

14. Якын туганнарыгыз (әтиегез, әниегез, абыйларыгыз, сеңелләрегез һәм балаларыгыз), шулай ук ир (хатын), шул исәптән чит илдә даими яшәүче һәм (яки) даими яшәү урынына чыгу өчен документлар рәсмиләштерүче туганнарыгыз (әтиегез, әниегез, абыйларыгыз, сеңелләрегез һәм балаларыгыз)

______________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, алар кайсы вакыттан бирле чит илдә яши)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

14. Ирнең (хатынның) гражданлыгы (подданство). Әгәр хатынның (ирнең) Россия Федерациясе гражданлыгы юк икән яисә Россия Федерациясе гражданлыгыннан тыш, чит ил гражданлыгы (подданство) булса (дипломатик ранг бирү каралган федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен Россия Федерациясе Чит эшләр министрлыгы системасында федераль дәүләт граждан хезмәтенә кергәндә тутырыла)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

15. Чит илдә булу (кайчан, кайда, нинди максат белән) ______________________________

______________________________________________________________________________

16. Хәрби бурычка мөнәсәбәт һәм хәрби исем ______________________

17. Өй адресы (теркәлү адресы, фактта яшәү), телефон номеры (яки башка элемтә төре) ______________________

18. Паспорт яки аны алмаштыручы документ ______________________

(серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

19.Чит ил паспорты булу ______________________

(серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

20. Шәхси счетның иминият номеры (булганда) ______________________

21. ИНН (булганда) ______________________

22. Өстәмә мәгълүмат (сайлау вәкиллекле органнарында катнашу, үзегез турында хәбәр итәргә теләгән башка мәгълүмат) ______________________

23. Анкетада ялган мәгълүматлар бирү һәм квалификация таләпләренә туры килмәвем конкурста катнашудан мәхрүм ителүгә һәм Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенә яки Россия Федерациясендә муниципаль хезмәткә кабул итүдән баш тартуга китерүе турында мәгълүм.

Миңа карата тикшерү чаралары үткәрү һәм минем шәхси мәгълүматларны эшкәртү (шул исәптән автоматлаштырылган эшкәртү) белән килешәм.

"__" _______________ 20__ ел Имза_____________

М. у.

Рәсмиләштерелүче затның фотографиясе һәм хезмәт эшчәнлеге, хәрби хезмәте, белеме турындагы мәгълүматлар шәхесне раслаучы документлардагы язмаларга, хезмәт кенәгәсенә, белем һәм хәрби хезмәт турында документларга туры килә.

"____" _____________ 20__ ел
_____________________________________________

(имза, кадрлар хезмәте хезмәткәре фамилиясе)